**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2020 елның «03» ноябреннән № 2

“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Шахмай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2020 елның 21 ноябренә сәгать 10.00 да Чаллы Башы балалар бакчасы янында (1 Май урамы 27 йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чаллы Башы авылы халкы белән Шахмай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 21 ноябренә сәгать 14. 00 да Чаллы Башы мәдәният йортында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чаллы Башы авылы халкы белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Шахмай авылы халкы исемлеген сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
4. Гражданнар җыененың этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслаута:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чаллы Башы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Шахмай авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

-җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- зиратны төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, капкалар урнаштыру, коры агачларны кисү, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмайавылының мәгълүмат стендларында урнаштырырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Башлыгы И.Г.Гаризов